ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.11.2022 Казан ш. № 515-2/г-2022

Татарстан Республикасы халкына сатыла торган табигый газга 2023 елга ваклап сату бәяләрен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Халыкка сатыла торган газга ваклап сату бәяләрен җайга салу буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2011 елның 27 октябрендәге 252-э/2 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 16 ноябрендәге 37-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы халкына сатыла торган табигый газга ваклап сату бәясен 6,78 сум/куб.м күләмендә билгеләргә (өстәмә хакка салым бәясен исәпкә алып).
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән табигый газга ваклап сату бәясе 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.
3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы халкына сатыла торган табигый газга ваклап сату бәяләрен билгеләү турында» 15.06.2022 №73-1/г-2022 карарын 2022 елның 1 декабреннән гамәлдән чыккан дип танырга.
4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев